• РУХИ МИРАС •
ГАЛИМНӘРЕБЕЗНЕ ТАНУ ҺӘМ ХӨРМӘТ ИТҮ
4 бит

• ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА •
САЛАВАТЛАР
7 бит

• НӘСЫЙХӘТ •
ГЫЙБАДӘТ ӨЧЕН ВАКЫТ ТАБУ
12 бит

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
ШИГЪРИ САБАКЛАР
14 бит



№ 9 (314) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | мөхәррам-сафәр, 1443

сентябрь, 2021


# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ



*Пәйгамбәрләрнең иң ахыргысы, иң нурлысы, Аллаһы каршында иң яратканы – ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньяга пәйгамбәрләрнең ахыргысы булып, нигъмәт буларак җибәрелә. Аллаһының Расүле бу дөньяга килгән вакытта дин зәгыйфьләнгән, кешеләр рухи бушлыкка, түбәнлеккә төшкән булалар…*

*Дәвамы 6 нчы биттә*

# Диния нәзарәте Пленумының күчмә утырышы узды

*Чираттагы Пленум утырышында мөфти мөхтәсибәтләрне «1100-еллык режимына» күчәргә чакырды*



Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

***16нчы сентябрь көнне Чистай районы мөхтәсибәтендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумының күчмә утырышы узды. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре, шулай ук район башлыгы Дмитрий Иванов һ.б. катнашты.***

Чара Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллинның Коръән аятьләрен укуы белән башланды. Пленум утырышының сәркатибе итеп бертавыштан мөфтинең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов сайланды.

Пленумның җыелышына төп сәбәп булып 4 сорау торды: Нәзарәтнең Президиум, Голәмәләр шурасы, Казыйлар шурасы, Аксакаллар шурасы составларын сайлау. Әлеге мәсьәләләр буенча Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул шулай ук агымдагы елның Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүен һәм Рәсәйдә халык санын алу кампаниясе якынлашып килүен искә алды. Хәзрәт милли-дини үзаңны үстерүдә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү эшендә мәчет-мәдрәсәләр алгы сафларда торуын искәртте. Моннан тыш, мөфти имам-мөхтәсибләргә һәм җитәкчеләргә киләсе елда Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100-еллыгы үткәрелү хакында әйтте һәм бөтен эшчәнлекне шушы зур датага багышлап, «1100-еллык» режимына күчәргә чакырды.

Алга таба пленум әгъзалары тарафыннан Диния Нәзарәте Президиумның 11 әгъзасын, Казыйлар шурасын, Голәмәләр шурасының рәисен һәм әгъзаларын сайлау, Аксакаллар шурасының рәисен һәм әгъзаларын сайлау булып узды. Җыелыш тәмамлану белән үк яңа составтагы Президиумның тәүге утырышы узды: анда әлеге киңәшче органнарның сайланып куелган командалары расланды.

Җыелыш ахырында дини эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендә аеруча нәтиҗәлелек күрсәткән һәм юбилейлар уңаеннан имам-мөхтәсибләр бүләкләнде. Милләтләр һәм диннәр арасында татулыкны ныгыту, исламның асыл кыйммәтләрен үстерү һәм Диния нәзарәтендәге уңышлы хезмәтләре өчен Диния нәзарәтенең III дәрәҗә «Мәрҗани» орденын Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Диния нәзарәтенең «Бердәмлек» медален Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин һәм Нурлат районы имам-мөхтәсибе Наил хәзрәт Әбелханов алдылар.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Мөселман яшьләре көч сынаша




Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

### Казанда мөселман яшьләре «MuslimQuiz» акыл көрәшендә көч сынашты

23 нче сентябрьдә Диния Нәзарәтендә мөселман яшьләре өчен яңа проект — «MuslimQuiz» акыллы уеннары эшли башлады. Беренче уен «Экстремизмга — юк!» айлыгы кысаларында «Тату яшик!» исеме астында узды һәм милләтара толерантлык һәм төрле дин вәкилләре арасында татулык темасын ачты.

Беренче акыл көрәшендә алтышар кешедән торган 15 команда, шулай ук җанатучылар, кунаклар жюри катнашты. Шунысы игътибарга лаек, уенда Казан яшьләре генә түгел, ә Мәскәүдән, Түбән Камадан, Яшел Үзәннән махсус «MuslimQuiz»га дип килделәр. Уенчылар табышмакларга җавап эзләде, мантыйк мәсьәләләрен чиште, катлаулы интеллектуаль сораулар өстендә уйлады, ребуслар чиште, авазларның килеп чыгышын эзләде, танылган рекламаларның эпизодларын искә алды һ.б.

Уен «акыл һөҗүме» форматындагы 6 раундны күздә тота. Бер раундта 6 сорау. Барлыгы 2021-2022 ел сезонында «MuslimQuiz»ның 6 очрашуы узачак. Аларның нәтиҗәләре буенча, иң күп балл җыйган команда кыйммәтле бүләк алачак.

Бу юлы барлык призлы урыннарны Казан яшьләре алды. Киләсе уен октябрьнең икенче яртысында узачак.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Нәзарәт проекты янәдән гамәлдә

*Татарстан мөселманнары Дия нәзарәте «Ислам. Беренче адымнар» проектында катнашырга теләүчеләрне сигезенче тапкыр укырга чакыра. Халык арасында шактый популярлык казанган кыска вакытлы әлеге курсларга язылучылар 7 дәрестә (атнасына бер тапкыр) намаз уку күнекмәләрен һәм ислам дине нигезләрен булай үзләштерә алачак. Бүгенге көндә дәресләргә язылу бара.*

Беренче кереш дәрес 16 нчы октябрь көненә билгеләнгән һәм ул Татарстан мөфтияте бинасында (Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт, 3 нче кат) иртәнге сәгать 8.00дә үтәчәк. Ислам нигезләренә тәҗрибәле хәзрәтләр, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең актив волонтер яшьләре өйрәтәчәк. Аерым алганда, укучылар, «Ислам. Беренче адымнар» проектында катнашып, тәһарәт алу һәм намаз уку тәртипләрен өйрәнәчәк, гакыйдә фәненә караган төп төшенчәләр, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы, хәләл-харам, хаҗ, уразаның фазыйләтләре һәм тәртипләре белән танышачак.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты мөфтият тарафыннан беренче тапкыр 2018 елда дәгъват эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла башлады. Әлеге проект 5 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә вакыты булмаганнарга гыйбадәт нигезләрен үти башларга мөмкинлек бирү өчен махсус оештырылды. Җиде сезон дәвамында әлеге курсларда 650 кеше белем алды һәм намазга басты.

Әлеге дәресләргә теләгән һәркем йөри ала. Яшь буенча чикләүләр юк (+17). Дәресләр шимбә көннәрендә иртәнге сәгать 8.00дән көндезге сәгать 13.00гә кадәр Казанның Галиев мәчетендә (Габдулла Тукай урамы, 40) узачак. Белем бирү татар һәм рус телләрендә алып барылачак. Дәресләрне үткәрү планына шулай ук уку өчен кирәк булган материаллар тарату да кертелгән. «Ислам. Беренче адымнар» проектында катнашучыларның барысын да бүләкләр көтә.


Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

Проектта катнашу өчен ҮДО МДНнең MUSLIM MOL кушымтасына кереп, «Школа одного дня» проекты тамгасына басып теркәлергә кирәк. Шулай ук 16 нчы октябрьгә кадәр эш көннәрендә иртәнге сәгать 09.00дан кичке сәгать 17.00кә кадәр +7 (843) 237-86-18 телефонына шылтыратып та язылырга мөмкин.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты буенча дәресләр уза торган Галиев мәчетендә барлык санитар-эпидемиологик таләпләр дә исәпкә алыначак: белем алучылар медицина битлекләреннән булырга һәм антисептиклардан файдаланырга тиеш.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Татарстанда мәчет каршындагы курслар башлана


Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

*1 нче октябрьдән Татарстанда Ислам нигезләре һәм дини тәрбия буенча мәчет каршындагы курслар башлана. Быел бушлай дәресләр республиканың 700дән артык мәчетендә үткәреләчәк. Курсларга 25 меңләп тыңлаучы йөрер дип көтелә. Аларга 1500гә якын мөгаллим дини белем бирәчәк.*

Мәчет каршындагы курсларның дини тәрбия программасы 3 елга исәпләнгән. Дәресләр нигездә ял көннәрендә үткәрелә, ә аларны уздыру вакыты, кагыйдә буларак, тыңлаучыларның теләкләрен исәпкә алып билгеләнә. Курсларның күпчелегендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым укыту каралган.

Татарстан мәчетләре каршындагы курсларда белем бирү эшчәнлеге ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан расланган, укырга килүчеләрнең яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән «Дини тәрбия» бердәм программасы буенча алып барыла. Әлеге программа, заман таләпләрен исәпкә алып, һәрдаим камилләштерелеп тора. Курслар кысаларында ТР мөфтияте бердәм программасы тарафыннан тәкъдим ителгән түбәндәге фәннәр укытыла: «Әдәп-әхлак», «Гакыйдә», «Тәҗвид», «Коръән», «Фикһ», «Сира», «Гарәп теленең башлангыч курсы». Моннан тыш, кайбер мәхәлләләрдә хәдис, Ислам тарихы, Пәйгамбәрләр тарихы, иске татар теле һәм башкалар буенча өстәмә дәресләр үткәрелә. Мөгаллимнәр шулай ук төп дини йолалар (исем кушу, никах, җеназа һ.б.) турында беренчел мәгълүмат бирә.

Мәчетләр каршындагы курсларда «Дини тәрбия» программасы буенча бердәм уку әсбабы – «Ислам дине нигезләре» китабы гакыйдә, фикһ (ислам хокукы), ислам тарихы һәм әхлак кебек мөһим бүлекләрдән тора. Гакыйдә өлешенә караган барлык темалар Әбү Хәнифә мәзһәбе һәм Әл-Матуриди юнәлешенә нигезләнеп аңлатыла.

Мәчетләре булмаган яисә мәчет каршындагы курслар оештырылмаган җирлекләрдә яшәүче татарларга яки вакыты кысынкы булган милләттәшләргә дини белемне алырга беренче татар онлайн-мәдрәсәсе ярдәм итәчәк. Онлайн-мәдрәсә мәчет каршындагы курсларын сыйфат ягыннан яңа югары дәрәҗәгә күтәрде. Онлайн-мәдрәсә medrese.tatar адресы буенча урнашкан белем бирү платформасында эшли. Мәдрәсәдә шулай ук iOS һәм Android базасындагы смартфоннар өчен эшләнгән махсус кушымта аша да «кереп» укып булачак. «Татар мәдрәсәсе» дип исемләнгән мобиль кушымтаны кесә телефонына Play Маркет һәм App Store-да бушлай күчереп алырга мөмкин.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Галимнәребезне тану һәм аларны хөрмәт итү әһәмиятлелеге турында




Һәр мөселман кешесенең гомерендә бер тапкыр булса да «**... коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр**», – дигән аятьнең ишеткәне бардыр. Ләкин кайсыбызның бу аятьнең мәгънәсенә төшенгәне бар? Аллаһы Тәгалә ни өчен шулай дип әйтә микән дип, кайсыбызның уйлап караганы булды? Әлеге сорауга беркадәр җавапны аятьнең үзеннән дә табабыз. Аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«[Расүлем!] Аллаһының күктән суны иңдергәнен күрмәдеңме? Аның белән Без төрле төсле төрле җимешләр чыгардык. Таулар арасында да төсләре төрле – аклы, кызыллы һәм кап-каралары – бар. Кешеләрдән, [җир йөзендә] хәрәкәт иткән җанлылардан һәм терлекләрдән дә төсләре төрле-төрле булганнары бар. Коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр. Һичшиксез, Аллаһы – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:27-28

Күргәнебезчә, әлеге аятьтә Аллаһы Тәгалә төсләрнең һәм килешкилбәтләрнең күптөрлелегендә, карашлар һәм фикерләрнең төрлелегендә олы хикмәт яшеренгәнлегенә ишарә итә, һәм моның хикмәтенә төшенә алуның бердәнбер юлы итеп – мондый күптөрлелеккә бербөтен итеп карый белүне атый. Чөнки аятьнең башында да бөтен бу күптөрлелекне барлыкка китерә торган бердәнбер чыганак итеп – күктән иңгән су күрсәтелә. Без – мөселманнар өчен күктән иңгән иң мөһим чыганак – Коръән булганлыктан, бу мәкаләдә антропологлар, минералоглар яки биологлар хакында сүз бармас, гәрчә алар да илаһи билгеләр белән эш итүче галимнәр булсалар да, ләкин монда үз гомерләрен Коръәнне өйрәнүгә багышлаган галимнәр турында сүз барачак.

Күптән түгел генә «Хозур» нәшрияты тарафыннан күренекле шафигый галиме Мөхәммәд Касыйм Габдух Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле хезмәте рус теленә тәрҗемә итеп бастырылды. Әлеге хезмәт авторның докторлык диссертациясе булып тора. Бу хезмәтендә автор хәнәфи фикһы мәктәбенә нигез салучы имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига карата абруйлы урта гасыр галимнәренең әйткән тәнкыйди фикерләрен бергә туплап, җентекле анализ ясап, объектив бәя бирә. Шул рәвешле, автор Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи турында урта гасыр чыганакларындагы күп кенә мәгълүматларның ачыктан-ачык ялган һәм яла булуын исбатлый, андый фикер һәм караш ияләрен, атаклы галимнәр булуларына карамастан, көнчелектә, тар карашлылыкта һәм объектив булмауда гаепли. Мөхәммәд бине Әл-Хариси билгеләп үткәнчә, Әбү Хәнифә, имам Мәлик, Әхмәд бине Хәнбәл һәм имам Шафигый рахимәһумуллаһи кебек күренекле ислам галимнәренә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренең нигезендә наданлык, көнчелек һәм тар карашлылык ята. Тарих кабатлана, һәм бүген дә Коръән һәм хәдисләрнең асыл мәгънәсенә төшенмичә, өстән генә фикер йөртеп, башкаларның фикерләре белән санлашмау исламда тәкфир һәм сәләфилек хәрәкәтен китереп чыгарды. Анда һәркем үз-үзенә галим, мөфти, имам. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз һәм [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] аерылмагыз. Аллаһының сезгә биргән [игелек һәм] нигъмәтен истә тотыгыз. Сез [җәһилият чорында бик озак еллар буена бер-берсе белән сугышкан] дошманнар булган чакта, Ул [сезне Ислам дине белән шәрәфләндереп] күңелләрегез арасында [татулык һәм бер-берегезгә карата җылылык яратып] өлфәт бердәмлек барлыкка китерде, һәм сез Аның [бу] нигъмәте белән [бер-берләрен бик якын күргән] кардәшләр булдыгыз. Янә сез [кяферлегегез сәбәпле] Ут упкыны ярында чакта, [Мөхәммәдне [салләллаһу галәйһи вә сәлләм] җибәреп] Ул сезне аннан коткарды. Аллаһы аятьләрен сезгә шулай баян итә, бәлки, сез һидаять табарсыз. Арагызда [дини һәм дөньяви] хәергә [файдалы эшләргә] чакыра, яхшы гамәлләрне [кылуны] әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103-104

Шуны да белергә кирәк ки, чын галимнәр бер-берсен беркайчан да оппонент итеп күрмәгән, чөнки гыйлемне алар барысы да бер чыганактан – Коръәннән алганнар. Максатлары да бер иде – Аллаһының ризалыгы өчен халыкка хезмәт итү. Мәсьәләләрне хәл итү юллары төрле булса да, чара һәм кораллары бер – Коръән һәм сөннәт иде.

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның фикһ мәктәбе һәм методологиясе турында күп әйтелеп, күп язылганга күрә, бу мәкаләдә әлеге галим турында хәдис белгече буларак кына берничә сүз әйтеп китәсе килә. Мөхәммәд Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле китабында моның турында шулай диелгән: «Мөхәддисләр арасында хәдис тапшыручының компетентлылыгы аның хәдис тапшыручылар арасында тоткан абруе белән билгеләнә. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһидан хәдис ишетеп бүтәннәргә җиткерүчеләр – замананың иң күренекле мөхәддисләре иделәр. Алар ышанычлы булулары белән генә түгел, ә хәдис тапшыруда гадәттән тыш төгәллекләре белән дә аерылып торганнар. Хәдисне берәрсеннән кабул иткәнче, ул хәдиснең тапшырылу чылбырын (иснәдне) җентекләп тикшергәннәр. Әгәр хәдис тапшыручылар арасында ышанычлы булмаган берәү ачыкланса, шунда ук аны фаш иткәннәр. Ибне Мәһди һәм Ибне Әл-Мәдәнидән алып, Ән-Нәсаи һәм Әбү Давыд белән тәмамлап, Әхмәд бине Хәнбәл, Ибне Мәгыйн һәм Исхак бине Раһәвәеһ кебек хәдис өлкәсендәге урта гасыр тәнкыйтьчеләренең күбесе заманында үзләре дә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи шәкертләреннән хәдис алганнар. Бу – олы остазның югары әхлак һәм камил зиһен иясе булганлыгына һичшиксез бер дәлил булып тора».

Әмма Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Коръән-хафиз һәм хәдис белгече булып кына калмаган, хәтерендә сакланган гыйлемнәрнең көндәлек тормышта дөрес кулланылышын эзләп таба алуда ул аеруча сәләткә ия иде. Аллаһы Тәгалә аны аек акыл һәм гадәттән тыш хәтер белән бүләкләгән. Ул Коръән аятьләреннән һәм хәдисләрдән моңа кадәр табылмаган җавапларны таба ала торган булган һәм шул сәләте белән гади халык һәм галимнәр арасында югары абруй казанды. Хәтта замананың иң бөек мөхәддисләренең берсе – Сөләйман Әл-Гәмәш Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи турында болай дип әйтә торган булган: «Дөреслектә, сез факыйһлар – табиблар, ә без мөхәддисләр – бары тик даруханәчеләр генә!»

Үз гомерендә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи төрле мәсьәләләргә караган биш йөз меңгә якын фәтва чыгарган. Шулардан бары тик йөз егермесе генә урта гасыр галимнәрендә кайбер сораулар тудырган. Мөхәммәд Әл-Хариси үз хезмәтендә бу очракларның һәрберсен җентекләп тикшерә, һәм имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи чыгарган бу фәтваларның Коръән һәм сөннәткә каршы килмәвен дәлилли.

Әлбәттә, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның гадәттән тыш мондый тырышлыгы һәм эшчәнлеге югары даирә вәкилләренең игътибарын җәлеп итми калмаган. Әле өммәвилләрдән Ибне Хөбәйра идарә иткән дәвердә имам Әбү Хәнифә раһимәһуллаһига Куфа шәһәренең югары казые булырга тәкъдим ителгән иде. Ләкин галимне гаделсез идарәчегә хезмәт итү кызыктырмый, һәм ул түрә тәкъдимен кабул итмәгәне өчен ирегеннән мәхрүм ителә. Үлем җәзасыннан Әбү Хәнифә раһимәһуллаһины бары тик зирәклеге генә коткара, һәм ул Мәккәгә качып котыла. Туган Куфасына Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи өммәвиләр бәреп төшерелеп, габбасиләр хәлифәсе Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур идарә итә башлагач кына әйләнеп кайта. Бу еллар дәверендә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи сәхабәләр һәм табигыйннәр белән аралашып гыйлем туплый. Үз янында да күп кенә тыңлаучылар җыя. Шулар арасында мәлики мәзһәбен коручы – Мәлик бине Әнәс (имам Мәлик) рахимәһуллаһи да була. Моның турында имам Мәлик рахимәһуллаһи соңыннан үзе болай дип әйтә торган иде: «Мин шундый кеше янәшәсендә утырганым булды ки, каршыдагы баганаңы алтын дип әйтсә, моны һичшиксез исбатлый алыр иде!»

Куфага әйләнеп кайткач, имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның атаклы галим буларак абруе һәм дәрәҗәсе тагын да арта. Озакламый аны габбасиләр хәлифәсе Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур да югары казыйлыкка чакыра. Ләкин Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи бу юлы да әлеге тәкъдимнән баш тарта һәм шул сәбәпле янәдән ирегеннән мәхрүм ителә. Тоткынлыкта ул төрле җәзаларга дучар ителә, ләкин Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур галимне барыбер үз ягына аудара алмый. Нәтиҗәдә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи 67 яшендә Багдад төрмәсендә үлә.

Шулай итеп, имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи мисалында без «**... Коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр**» аятенең чын мәгънәсен аңлыйбыз. Ул – гомеренең соңгы көннәренә хәтле Коръән һәм сөннәттән өйрәнгән принципларга тугры булып калган чын мәгънәсендәге галим кеше.

Имам Әбү Хәнифәнең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле әлеге һәм күп кенә башка мәгълүматларны сез Мөхәммәд Касыйм Габдух Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле китабыннан укып белә аласыз.

■ **Альберт КАДЫЙРОВ**

# Муса һәм Хозыр галәйһиссәлам кыйссасы



Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Һәм Хозыр галәйһиссәлам болай дип сөйли башлаган:

«Тишек тишкән корабка килгәндә, ул үзләренә ипи өчен акча эшләгән бик яхшы кешеләрнеке иде. Әмма алар юнәлгән тарафта бик тә гаделсез дәүләт башлыгы идарә итә. Бу вәхши бөтен яхшы корабларны үзенеке итеп үзләштерә торган булган. Корабта тишек ясап, ике явызлыкның кечкерәген сайлап, мин аларны хакимнең усаллыгыннан коткардым һәм шуның белән аларга ярдәм иттем.

Балага килгәндә, ул игелекле һәм гадел гаиләдән иде. Киләчәктә бу сабый начар юлдан китеп, хәтта әти-әнисен дә юлдан яздыра алыр иде. Шуңа күрә, үсеп башкисәргә әверелгәнче без аны һәлак иттек. Аңа алмашка Аллаһы Тәгалә бу кешеләргә итагатьле бала бүләк итәчәк (Бер риваятьтә Аллаһы Тәгалә бу игелекле бәндәләргә киләчәктә бер пәйгамбәрнең әнисе дәрәҗәсенә лаек булырлык кыз бүләк иткән, дип хәбәр ителә).

Авыл читендәге диварга килгәндә, ул ике ятим баланың җир биләмәсендә урнашкан булган. Бу дивар астында алар өчен яшерелгән хәзинә сакланган. Аларның әтиләре изге кеше булган һәм шушы дивар астына үз балаларына хәзинә яшергән, ә аның сакланышын Аллаһыга ышанып тапшырган. Әгәр шушы дивар бу ятимнәр үсеп җиткәнче җимерелсә, авыл халкы шул хәзинәне табып алып, аларны талап бетергән булырлар иде. Аллаһы Тәгалә ятим балаларның балигълык яшенә ирешүләрен һәм бу хәзинәне табуларын теләгән. Болар барысы да Аллаһының рәхмәте буларак эшләнгән. Мин эшләгән барлык гамәлләремне үз теләгем белән эшләмәдем: бу минем бурычым иде, миңа бу вазифам Рәхимле Раббыбыз тарафыннан бирелде. Минем гамәлләремнең хакыйкый асылы нәкъ менә шунда».

Хозыр галәйһиссәламнең әлеге сүзләре шулай ук Коръәндә дә расланa:

**«Алар [кыя янына килеп җиткәч] колларыбыздан [Хозыр [галәйһиссәлам] исемле] бер колны таптылар, Без аңа хозурыбыздан бер рәхмәт биргән, Үзебездән бер гыйлем өйрәткән идек [Безгә генә хас һәм Безнең өйрәтүебездән башка беленүе мөмкин булмаган «ләдүнни гыйлем» аша ул гаибкә караган кайбер нәрсәләрне белә иде]».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:65

Бу аять белән «Әл-Кәһф» сүрәсендә Муса һәм Хозыр галәйһимәссәлам тарихын бәян итү башланып китә һәм ул 82 нче аятькә кадәр тәфсилләп тасвирлана.

Бу вакыйгаларда Муса галәйһиссәлам өчен тагын бер мөһим мәгънә яшеренгән була. Хозыр галәйһиссәлам белән аерылышырга туры килсә дә, аның белән танышу нәтиҗәсендә, Муса галәйһиссәлам бөтен гомере буена уйлап йөргән мәсьәләләрнең мәгънәсенә төшенә башлавын аңлый:

1) Ни өчен аның әнисе, Фиргавен кешеләре баланы үтерерләр дип курыкса да, аны сандыкка салып Нил елгасына агызган, шулай булса да Муса галәйһиссәлам һәлак булмаган?

2) Кыерсытылган Исраил улын коткарам дип, Муса галәйһиссәлам кыптыйны һәлак иткән. Аллаһы Тәгалә аңа ни өчен шундый насыйп биргән? Бу хәлгә аның бик тә каефе кырылган.

3) Ни өчен Муса галәйһиссәлам Шугайб галәйһиссәлам кызларының сарыкларын сугарган һәм моның өчен алардан акча алмаган?

Муса галәйһиссәлам бу сорауларга җаваплар тапсын өчен Раббыбыз аның юлына Хозыр галәйһиссәламне җибәрә дә инде. Зирәк акыл иясе белән бергә кичергән вакыйгалар аңа Аллаһы Тәгаләнең Рәхимле Зат булуына тагын бер кат инанырга ярдәм иткән. Хозыр галәйһиссәлам кораб идәнен тишкәндә аңа болай дип әйткән:

– Ий Муса! Әниең сине сандыкка салып суга агызып җибәрде, ләкин син батмадың. Аллаһы Тәгалә сине саклады, димәк, ул бу кешеләрнең дә гомерләрен саклаячак.

Ниһаять, Хозыр галәйһиссәлам Муса галәйһиссәламнең Шугайб галәйһиссәлам кызларының сарыкларына су эчертүен һәм аның өчен бернинди түләү алмавын искә төшергән. Бер авыл читендә урнашкан диварны төзәткәндә дә Хозыр галәйһиссәлам нәкъ шулай ук бер тиен дә хак алмаган: «Мондый эшләрне акчага эшләмиләр», – дип аңлаткан ул.

Хозыр галәйһиссәлам Аллаһы биргән белемнәрнең бер өлеше белән шул рәвешчә уртаклашкан. Фикер йөртүчеләр әлеге хикәятләрдән үзләре өчен олы файда алып, чын хакыйкатьне аңларлар, дип ышанам. Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән безгә килгән һәр бәла-казада нинди дә булса мәгънә бар. Аллаһы Тәгалә биргән тәкъдиребездә безгә Үзенең яшерен хикмәтләренә төшенергә ярдәм итсә иде, ә тормышыбызда Аның тарафыннан тәгаенләнгән вакыйгалар безнең өчен яхшы нәсыйхәтләр булсыннар. Аллаһы Тәгалә барысын да яхшы Белүче.

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

# Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән...

***Галәмнәрне юктан бар итеп, безгә иксез-чиксез нигъмәтләрен биргән, безнең тәнебезгә җан керткән һәм Үзенең рәхмәтендә яшәргә мөмкинлек биргән Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барча мактаулар булса иде һәм дә галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган, безнең калебләребезнең табибы, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән безгә туры юлны күрсәткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салаватшәрифләребез булса иде.***

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә бу дөньяны халык кылганнан соң, адәм балаларын шушы дөнья «мәдрәсәсенә» җибәрә. Адәм баласы һәрвакытта нәсыйхәтләргә, яхшы киңәшкә һәм дөрес юлны күрсәтүгә мохтаҗ. Шул сәбәпле, нинди генә кавемнәр, нинди генә халыклар яшәсә дә, Аллаһы Тәгалә адәм балаларына рухи укытучыларны җибәргән. Рухи укытучылар дөнья малына баткан кешеләргә җаннарын ризыкландырырга ярдәм иткәннәр. Шушы укытучылар адәм балалары арасыннан иң хәерлеләре. Алар – пәйгамбәрләр. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә аларны безгә нәсыйхәт итеп, бер нур итеп, шушы дөньяның пычраклыгына баткан, күп вакыт наданлыкка төшкән бәндәләрне дөрес юлга бастырыр өчен рухи укытучылар итеп җибәргән. Алар бихисап. Әмма араларыннан Аллаһы Тәгалә олылап, Үзенең китапларында бәян иткәннәре бар. Пәйгамбәрләрнең иң ахыргысы, иң нурлысы, Аллаһы каршында иң яратканы – ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньяга пәйгамбәрләрнең ахыргысы булып, нигъмәт буларак җибәрелә. Аллаһының Расүле бу дөньяга килгән вакытта дин зәгыйфьләнгән, кешеләр рухи бушлыкка, түбәнлеккә төшкән булалар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм килеп, 63 ел гомере аралыгында йөз меңләгән сәхабәне тәрбияләп калдырган. 40 яшендә аңа пәйгамбәрлек килгән. Үз тормышында нинди генә авырлыклар булуына карамастан, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да сынмаган, сыгылмаган, Раббысының ярдәмен тоеп яшәгән. Бер Аллаһы Тәгаләгә генә инанып, Аннан гына ярдәм өмет иткән. «Өммәтем, өммәтем, өммәтем», дип әйтә-әйтә, төннәр буе намазларын укыган, күп догалар кылган. Һәрвакытта кешеләр тынычлыгы, иминлеге хакына нәсыйхәтләрен ирештереп, изге гамәлләр башкарган. Үзенә начарлык эшләгән кешеләргә дә начарлык белән җавап кайтармаган. Киресенчә, яхшылык белән җавап кайтарган. Гомумән, бу үзе зур үрнәк булып тора. Аның мәрхәмәтлелеге турында, киң күңеллелеге хакында бик күп вакыйгалар бар.

Бервакыт бер бәдәви гарәбе мәчет эченә кереп, үзенең йомышын башкарган. Сәхабәләрнең бу күренешкә ачулары чыгып, алар бу бәндәгә ябырылганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны тынычландырып, шушы нәҗесле җиргә бер савыт белән су алып килеп, шуны сибәргә кушкан. Ул беркайчан да начарлыкка, әдәпсезлеккә өндәмәгән. Сәхабәләр аннан: «Аллаһы Тәгалә бу дөньяга сине нәрсә өчен җибәрде?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Күркәм әдәпне вә әхлакны югары рәвешкә җиткерер өчен», – дип җавап кайтарган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм акыллы, нурлы, пакь күңелле булган. Аның күңелендә усаллык булмаган. Күңелендә ризасызлык булса да, ул фәкать Аллаһы Тәгаләнең динендә ярамаган, булмаган эшләрнең эшләнүенә ризасызлыгын белдергән. Беркайчан да кешене рәнҗетмәгән, начар сүзләр белән эндәшмәгән. Әгәр дә аз гына ялгышса, һәрвакыт гафу үтенә торган булган.

Аллаһы Тәгалә сөекле Пәйгамбәребезне туганда ук пәйгамбәрлек нуры белән бүләкләгән. Аллаһының Расүле сабый яшеннән үк ятим калган. Ул туганчы ук аның әтисе вафат булган. Ул туып, бераз вакыт яшәгәннән соң, аның әнисе дә бакыйлыкка күчкән. Соңыннан бабасының тәрбиясенә калып, бабасы вафат булганнан соң, Әбү Талиб исемле абзасының гаиләсендә тәрбияләнгән.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кечкенә яшеннән үк бик зирәк, акыллы, күркәм холыклы, ышанычлы булган. Шуңа күрә Мәккә халкы аңа «Мөхәммәд, «Әл-Әмин» дип эндәшкән, ягъни ышанычлы, әманәтне саклый, беркайчан да үзенең вәгъдәсен бозмый, ялганламый, кешеләргә начарлык эшләми дигән сүз. Шул сәбәпле, аңа шундый олы исем биргәннәр.

40 яше җиткәч, мәгарәдә утырган вакытында аның янына Җәбраил галәйһиссәлам килгән. Шушы мизгелдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи иңә башлаган. Аллаһының Расүле иң элек бу вакыйгалардан курыккан, ләкин соңрак үзенең пәйгамбәр итеп җибәрелүен белгән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм 23 ел дәвамында дәгъват кылган. Бакыйлыкка күчеп, үзеннән соң йөз мең сәхабәне калдырган. Шушы сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң Ислам динен бөтен дөньяга таратканнар. Алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен, Аллаһы Тәгаләнең Китабын бөтен нәрсәдән дә өстен куеп, Аллаһы Тәгаләне нык яратып, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне әти-әниләренә караганда да ныграк яратып, аны үзләренә үрнәк итеп алганнар. Без дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үзебезгә үрнәк итеп алсак, һичшиксез, Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә безгә бик яхшы тормыш бирер иде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән безне тынычлыкта яшәр идек, иншәАллаһ.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына карасак, аның хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә һәрвакыт аның янында булган, кызлары аңа һәрвакыт ярдәм иткәннәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә нинди генә сүзләр әйтсәләр дә, нинди генә әшәкелекләр кылсалар да, ул беркайчан да аларга начарлык белән җавап кайтармаган.

Таиф шәһәреннән аны ташлар атып куып чыгарганнар. Бик яраланган булса да, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга бәддога кылмаган. Киресенчә, ул аларга хәерлесен теләп дога кылган.

Мәккә мөшрикләре аның артыннан куып эзләгән вакытта, якын сәхабәсе Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән мәгарәдә булганда, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл итәргә кушкан. Хәтта үрмәкүч мәгарәгә пәрәвез ясап куйган. Агачлар, үсемлекләр, ташлар да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәрвакыт салават әйтә торган булганнар. Аллаһының Расүле ятимнәргә, тол хатыннарга, мескен фәкыйрьләргә бик яхшы мөнәсәбәттә булган. Ул иң күркәм әхлак иясе булган. Хатыны Гайшә анабыз «Аның әхлагы нинди иде?» дигән сораугa: «Аның әхлагы Коръән иде», – дип җавап кайтарган. Ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгалә иңдергән Коръәни Кәрим аятьләренә туры китереп яшәгән.

Әйткәнебезчә, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакытта ятимнәргә, мескеннәргә ярдәм иткән. Йортында аз гына ризыгы булса да, ул аның белән бүлешкән. Төннәр буе намаз укып, дога кылып, өммәте өчен иң хәерлесен сораган. Ач булган вакытында да зарланмаган.

Бервакыт Билал исемле мөәзине Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең янына килеп зарланган. Кара тәнле булганга, берәү аңа: «Син кара хатынның улы», – дип әйткән. Билал радыяллаһу ганһе бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгәч, Аллаһының Расүле Билал радыяллаһу ганһегә начар сүзләр әйткән сәхабәгә: «Синең күңелеңдә әле җәһиллек калган икән», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсыйхәтләре шуның кадәр үтемле булган ки, тиз арада Билал радыяллаһу ганһе янына барып, аннан гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән хәтта Җәбраил галәйһиссәлам дә иң күркәм сүзләр белән эндәшкән. Аллаһының Расүленә «Хәбибулла» дип тә дәшә торган булганнар, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең яратканы. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә аны иң хәерле рәвештә, иң олы дәрәҗәләргә күтәрә. Кыямәт көнендә дә, бөтен кешеләр куркып басып торганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәфәгать кылачак. Аның яратуына ирешергә теләгән һәр мөселман аңа иксез-чиксез салаватлар әйтеп, догалар кылып, аны чын күңелдән яратып, аңа охшарга тырышып яшәргә тиеш һәм шушы очракта Аллаһы Тәгалә безне яратыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә гыйлем мирасын, күркәм әдәп-әхлак калдыручыларның иң хәерлесе, безнең калебләребезнең табибы, рухи укытучыбыз, үрнәк алырдай затыбыз. Шул сәбәпле, Аллаһы Тәгалә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күркәм әхлак белән охшарга, аны яратырга, аңа һәрвакыт салават әйтергә насыйп вә мәяссәр кылса иде һәм дә Кыямәт көнендә шәфәгатьчелеген насыйп кылып, турыдан-туры җәннәтләргә кертсә иде. Рабигыльәүвәл аенда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган аенда, без Расүлебезне зурлап салаватлар әйтик, бөтен мөселман дөньясы аны иң хәерле рәвештә искә алып, һәр мөселман берберсенә карата Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм васыять иткән мәхәббәтне булдырса иде. Бер-беребездән гафу үтенеп, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакына булса да берберебезгә яхшы мөнәсәбәттә булсак иде. Әмин.

■ **Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ,** Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе, Сатыш авылы имам-хатыйбы

# Салават



Фото: shutterstock.com

***Гарәп телендә «салават» сүзе «салят» сүзенең күплек сан төре. Ул «намаз», «дога» мәгънәсендә килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават – мөселманнарның аңа карата яратуларын, рәхмәт һәм хөрмәт хисләрен, Расүлебезнең Кыямәт көнендә шәфәгатенә өметләнүен белдерүе ул.***

Пәйгамбәребезгә салават әйтү – аның исемен әйткәннән соң «Салләллаһү галәйһи вә сәллам» дип өстәү ул.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Биредә Аллаһы Тәгаләнең салават әйтүе – аны фәрештәләр алдында мактавын белдерә, фәрештәләрнең салават әйтүе – аның өчен дога кылуларын аңлата.

## Нәрсә ул салават?

Әбү Галия исемле хәзрәт әйтүенчә, салават – Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне, Раббыбызның хәбибен мактавыны аңлатыр. Фәрештәләрнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлары – аларның истигъфарларыдыр. Кешеләрнең салаваты – хәер-дога әйтү, игелек теләүдер. Аллаһы Тәгалә Үзенең хәбибен яраткач, якын күргәч, аңа салават әйтү Аллаһы Тәгаләдән үзеңә хәер-дога алу белән бер. Хәзрәти Габдулла бине Гамер әйтүенчә, кем булса да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бер салават әйтсә, әйтүче Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның фәрештәләреннән 70 салаватка ирешер. Пәйгамбәребез үзе дә: «Кем булса да миңа бер салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун салават булдырыр, кем 10 салават әйтсә – Аллаһы Тәгаладән 100 гә ирешер. Кем миңа 100 салават әйтсә – Аллаһы Тәгалә аңа икейөзлелектән котылуны һәм уттан котылуны насыйп итәр һәм Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аны шәһитләр белән бергә булдырыр», – дигән.

Фазыйләтле салаватның берсе – «Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галә әәли Мүхәммәдин вә сәллим» дип әйтү. Тик әйтүче кеше бу салаватларны әйткәндә, «салли» сүзендә басымны «а» авазына куярга тиеш, чөнки «салли» дигәндә басымны «и» авазына куйса, бик олы көферлек кылуы бар!

## Салават әйтүнең файдалары

1. Аллаһының әмерен үтәү.

**«Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

2. Салават әйтү, Аллаһының рәхмәте белән, безнең гөнаһларыбызның кичерелүенә китерә.

Пәйгамбәребез: «Миңа бер салават әйтүче кешегә Аллаһы 10 салават әйтер, 10 гөнаһын ярлыкар һәм 10 дәрәҗәгә күтәрер», – дигән.

3. Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенә салаватлар әйткән кеше белән бергә булыр.

Ул: «Кыямәт көнендә кешеләр арасында миңа иң якыннары булып, миңа иң күп салаватлар һәм сәламнәр әйтүче булыр», – дигән.

4. Пәйгамбәребез әйтелгән сәламнәргә җавап кайтара.

Ул: «Әгәр кем дә булса миңа сәлам бирсә, мин ул кешенең сәламен кабул итә алсын өчен, Аллаһы Тәгалә миңа җанымны кайтарыр», – дигән (имам Әбү Давыд, имам Әхмәд).

5. Шулай ук Расүлебезгә салаватлар әйтүче кешенең холкы күркәмләнә, ул начар гадәтләрдән арына, Аллаһының ризалыгына ирешә, ике дөнья бәхетенә лаек була һәм тормышына бәрәкәт иңә.

## Салават шәрифләр

Бөтен мөселманнар салават шәрифне бик күп итеп укырга тиеш. Салават шәрифне күп укыган кеше бәла һәм афәтләрдән, кайгыхәсрәттән һәм фәкыйрьлектән имин булыр, хәерле максатларга ирешер. Бигрәк тә җомга көннәрендә күп итеп уку яхшы.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә иман вә ислам әһеленә Үзенең һәм фәрештәләренең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйткәнне тантаналы хәлдә ачыклый, белгертә. Моның хакында югарыдагы аятьтә искә алынды. Димәк, киресенчә эшләү Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһы Тәгалә каршында булган дәрәҗәсенә әһәмият бирмәү белән бердер.

Бүгенге көнне Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исеме китапларда, язмаларда язылганда бик күп очракларда янында «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» дип язу урынына, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәрәҗәсенә игътибар итмичә, «г.», «г-м», «с.г.в.с.», «с.л.г.м.» кыяфәтле кыскартмалар очрый. Кыямәт көнендә шәфәгатен өмет итеп, азаннар әйтелгән саен «вәрзүкъны шәфәгатәһү Йәүмәл-Кыйәмәһ» («вә Кыямәт көнендә безгә аның шәфәгатен насыйп әйлә!») дигәндә, Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеме янында «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» җөмләсен язудан нәрсә өчен үз-үзебезне тыябыз соң? Кәгазь саклыйбызмы? Әллә буяунымы? Бәлки бу нәрсә ялкаулыктан килеп чыгадыр? «Белмәдем, белмәдек» диючеләр булса, киләчәктә болай эшләүдән сак булсагыз иде.

## Расүлебезгә салават әйтүнең мөһимлеге

Раббыбыз әманәткә биргән нәрсәләрне ияләренә кайтаруны, әманәт үтәүне таләп итә, әманәткә хыянәт кылудан катгый хәлдә кисәтә. Шул әманәт дигән нәрсәләрнең берсе – дөньяларга Аллаһы Тәгаләнең Үз рәхмәтеннән күндерелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә салават әйтү булыр.

Салават әйтүнең фазыйләтләре турында күп сөйләнә. Тик без әманәт үтәүдә күбесенчә гафил булып калабыз. Шул мәсьәләгә янә кайтып, гакыл ияләренең игътибарын җәлеп итәргә булдык. Аллаһы Тәгалә бу эштә безгә иң олы ярдәмче, иң олы киңәшче булса иде! Рувәйфәгъ бине Сәбит Әл-Әнсаридән риваять ителгәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем «Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә әнзилһүлмәкъгадәл-мүкаррабә гыйндәкә йәүмәл-кыйәмәһ» (мәгънәсе: Йә Аллаһым! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватың булса иде! Һәм Син аны Кыямәт көнендә Үзеңә якынайтылган хөрмәтле дәрәҗәгә ирештерсәң иде!) дип әйтсә, аңа – минем шәфәгатем тиеш булыр», – дигән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең каршында олы дәрәҗәгә, Мәками мәхмүдкә ирешсә иде, дип без һәр азан әйтелгән саен дога кылабыз. Безнең дога кылуларыбыз, иншәАллаһ, бушка китмәс.

«Кыямәт көнендә миңа иң якыныгыз – үземә күпләп салават әйтүчегез булыр!» – дигән Расүли Әгъзам. Хәзрәти Гали радыяллаһу ганһенең риваятендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен ишетеп тә, аңа салават-сәлам әйтмәүче саранның сараны булыр, дигән мәгънәдә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен тапшырып калдырылган.

Хәзрәти Әбү Һөрайра риваяте буенча бу кисәтү: «Хур булсын шул кеше, кем дә кем мине искә алу белән үземә салават әйтмәсә», – дип яңгырый.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исемен «Мөхәммәд» дип кенә, ягъни «Пәйгамбәребез Мөхәммәд», «Расүлебез Мөхәммәд» дип әйтмичә сөйләшү, Расүлебезнең дәрәҗәсенә карата илаһи әмерне үтәмәү була.

Шәех яки ишан-хәзрәт Габдулла Сираҗеддин «Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү» дигән китабында салават әйтә торган вакытлардан иң хәерлеләренең егермесен санап күрсәтә. Ул 20 төрле вакытлар түбәндәгеләрдер:

1. Азан әйтеп бетергәч, азан догасыннан соң.
2. Дога кылганда салаватны доганың башында, уртасында һәм ахырында әйтү.
3. Мәчеткә кергәндә.
4. Бер мөселман икенче берәү белән очрашканда.
5. Берәр мәҗлескә җыелганда.
6. Берәр язуда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исемен язудан соң.
7. Һәр хәерле сүз, фикер әйткәндә.
8. Вәгазь сөйләгәндә, дәрес укыганда.
9. Көннең башында һәм ахырында.
10. Йокы килгән вакытта.
11. Төнлә йокыдан торып, төнге намазларга басканда.
12. Колаклар тонган вакытта.
13. Хәдис-шәриф онытылганда.
14. Салаватлар әйтүдән соң.
15. Коръәнне хәтем итүдән соң.
16. Гамь, хәсрәт вакытында.
17. Берәр теләк-хаҗәт булып дога кылганда.
18. Никах хотбәсен укыганда.
19. Җомга көнендә һәм кичәсендә.
20. Хаҗ гамәлләрен үтәгәндә.

Әлбәттә, салават бу 20 вакытта гына әйтелер дә, башка чакта әйтелмәс дигән сүз түгел. Бу 20 урын салават әйтүгә бик хөрмәтле булган вакытлар гына.

■ **«Догалык»** китабыннан

# Мохтаҗларга гошер садакасы таратыла башлады

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды гошер садакасын тарата башлады. Яшелчәләрнең беренче партиясен 2 тонна күләмендә Татарстанның Питрәч һәм Алексеевск мөхтәсибәтләре тапшырды. Бәрәңге, кабак, чөгендер, кәбестә, кишер һәм ташкабак күпбалалы, аз керемле гаиләләр һәм авыру кешеләргә – барлыгы 30 гаиләгә өләшенде. Акция дәвам итә.***



Билгеле булганча, Татарстанда Диния Нәзарәте башлангычы белән, гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе башланды һәм 2021 елның 25 сентябре Татарстанда Гошер көне дип игълан ителде.

Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер садакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә: бәрәңге, кәбестә, аш чөгендере, кишер, кабак, суган, алма, слива һ.б. Аннары азык-төлек җыелмаларын аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак.

Казанда гошерне Нәзарәт карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм тарата. Фондта меңнән артык мохтаҗ гаилә исәптә тора, аларның барысына да – күпбалалы, тулы булмаган, азкеремле, авыру балалар тәрбияләүче гаиләләргә – гошер тапшырылачак. Әлеге исемлектә булмаган, ләкин гошер рәвешендәге азык-төлеклә тә ярдәмне алырга теләүчеләр, керемнәре турындагы белешмә алып, +7 (843) 225-33-22 телефоны буенча шалтыратып фондка мөрәҗәгать итә ала. Гошер алып килергә теләүчеләр, шушы ук номерга шалтыратып, сорауларын бирә ала. Гомумән, гошер мохтаҗларның милләтенә һәм диненә карамыйча, аларның үзләренә, шулай ук хәйрия оешмаларына, социаль учреждениеләргә (район картлар йортлары, балалар йортлары, балалар хосписы), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләргә, мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына, Коръән-хафизлар әзерләү үзәгенә һ.б.) тапшырылачак.

Гошер – садаканың махсус төре, ул мөселман кешесенең үстергән уңышын җыеп алганнан соң, аның уннан берен мохтаҗларга бирүдән гыйбарәт. Гошер садакасының мәҗбүри булуы хакында «Әл-Бәкара» сүрәсенең түбәндәге аятендә әйтелә:

**«Ий, иман китерүчеләр! [Кәсеп итеп] Тапканнарыгызның иң яхшыларын [хәләлләрен] һәм Безнең сезнең өчен җирдән чыгарган нәрсәләребездән [садака итеп] сарыф итегез...».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:267

Гошер садакасының мәҗбүри булуының асыл мәгънәсе – теләсә кайсы уңыш нигезендә Аллаһының рәхмәте ятуда, чөнки әлеге нигъмәтләр табигать шартларының уңай килүе нәтиҗәсендә өлгерә. Аллаһының рәхмәтенә ирешү һәм киләсе уңышка нигез салу өчен, Раббыбызның әмеренә буйсынып, Кәлам Шәрифтә әйтелгәнчә, уңышның гошерен (уннан берен) бирергә кирәк. Диния нәзарәте әлеге юнәлешкә бик зур дикъкать белән карый.

Инкыйлабка кадәр Ислам динен тотучы татарларда гошер садакасын җыю гадәти хәл булган. Ә советлар вакытында гошер бәйрәмнәрен уңыш бәйрәмнәре алмаштырган. Хәзер бу хәйрия гамәле Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якуповның идеясе белән яңадан республика мөселманнарының дини тормышына кире кайта башлады.

Татарстанда 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда –1109,5 тонна, 2020 елда якынча 1000 тонна гошер садакасы җыеп таратылган иде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан





Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

# Коръән безне әдәп-әхлакка өйрәтә

***Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә радыяллаһу ганһәдән Расүлебезнең әхлагы хакында сораганнар, ул: «Пәйгамбәребезнең әхлагы Коръән иде», – дип җавап биргән.***

Коръәни Кәрим безне әхлаклы, тәрбияле булырга өйрәтә. Һәм бәхетле буласыбыз килсә, без боларга игътибарлы булырга тиешбез. Коръәндә кеше тормышына кагылышлы булган һәр мәсьәлә дә яктыртылган. Без ярдәмчел, киң күңелле, ачык йөзле булырга тиеш. Әти-әниләребезгә, күршеләребезгә, туганнарыбызга, дусларыбызга, кардәшләребезгә, гомумән, янәшәбездә булган һәркемгә карата игътибарлы булу кирәк.

Коръәндә гаделлек, гадел булу дигән төшенчә бар. Бу – безнең янәшәдә булган кешеләрнең хакларын бозмау дигән сүз, ягъни кем генә булса да, без ул кешегә хөрмәт белән карарга, аны кимсетә, түбәнсетә торган сүзләр әйтүдән, гамәлләр кылудан ерак булырга тиеш. Бу әхлаклы мөселман кешесенең төп кагыйдәсе. Расүлебездән, мөселман кешесе кем ул, дип сорагач, ул: «Кулыннан да теленнән башкалар имин булган кеше», — дип җавап биргән.

Мөселман кешесе нинди сыйфатлардан качарга, аларны үзендә булырмаска тырышырга тиеш соң? Әлбәттә, тәкәбберлек (үз-үзеңне ярату), икейөзлелек, хәйләкәрлелек, башкалар турында начар сөйләү, сүз йөртү, көнчелек, ялган кебек сыйфатлар динебез тарафыннан тәнкыйтьләнә. Мөселман кешесе шушы сыйфатлардан котылырга тырышырга тиеш. Сүз дә юк, һәркемнең көчсез ягы була. Берәүләргә ялганлау гадәте хас, икенчеләр башкалардан көнләшә... Әмма иң мөһиме: үзеңнең гаебеңне тану һәм аны төзәтер өчен тырышлык кую. Бу очракта әлеге күркәм доганы уку күркәм гамәл булып тора.

Көзгедән караганда укыла торган дога:

اَللَّهُمَّ أَنْتَ حَسَّنْتَ خَلْقِى فَحَسِّنْ خُلُقِى


Фото: shutterstock.com


«Аллааһүммә әнтә хәссәнтә халькый фәхәссин хулүкый»

«Йә Аллаһы! Сурәтемне күркәм кылган кебек, холкымны да күркәм әйлә».

Раббыбыз холыкларыбызны күркәм итеп, безне динебезне матур яктан күрсәтүчеләрдән кылса иде

■ Сәхифәне
**Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

+12




## *«Хозур» нәшрият йорты «Ислам дине: яшүсмерләр өчен» дип аталган китап нәшер итте*

***Әлеге китап Ислам дине нигезләре белән таныша башлаган яшүсмерләр өчен әзерләнде. Хезмәтнең максаты – укучыларыбызга гади һәм аңлаешлы итеп, динебездәге мөһим төшенчәләрне, шәригать хөкемнәрен аңлату. Биредә намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек төп фарызларыбыз һәм аларның тәртипләре хакында да җентекләп аңлатылган.***

«Хозур» нәшрият йортының «Ислам дине нигезләре» китабына нигезләнеп әзерләнгән әлеге басма һәркем өчен дә файдалы китап булып, гыйлем алуда, шәригать мәсьәләләрен өйрәнүдә ярдәмлек вазифасын башкарыр дип уйлыйбыз.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм дистанцион рәвештә заказ бирергә мөмкин.

**Кибет: Казан шәһ., Париж Коммунасы ур., 6нчы йорт.**
**Тел.: +7 960 072-74-63;**
**Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.**
**Тел.: +7 (966) 250-00-09;**
**Интернет-кибет: huzurshop.ru**

(Дәвамы. Башы алдагы санда)

# Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе

*Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе – традицион Ислам инде ул. Ул – уттан котылганнарның карашлары, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр, сәләфләр һәм Кыяматкә кадәр аларга ияргән галимнәрнең карашлары.*

21. Мөэминнәр Аллаһыны Ахирәттә күзләре белән шәкелсез һәм урынга, тарафка нисбәтле булмаган рәвештә күрә алачаклар. Аллаһы, сурәткә һәм ниндидер якка нисбәтле булмаганлыктан, Аны күрү дә сурәткә яисә урынга бәйле булмаячак. Әмма кеше урынга бәйле булмаган әйберләрне күз алдына китерә алмый, чөнки бу дөньяда кешегә андый кодрәт бирелмәгән, ул мөмкинлек бары Ахирәттә генә биреләчәк.

22. Аллаһыны төштә күрү ихтималы бар, әмма төштә күргән шәкелнең Аллаһының Үзе булуына ышанырга ярамый, чөнки Аллаһының шәкеле юк.

Кайбер кешеләр Аллаһыны кайбер сурәтләрдә төшләрендә күрәләр, әмма бу сурәтнең Аллаһы булуына ышанырга ярамый.

23. Аллаһы – кешеләрне һәм гамәлләрен аларның сайлауларына туры китереп Яратучы, бу сайлаулары өчен кешеләр Кыямәт көнендә җавап бирәчәкләр. Бу җиһандагы бөтен вакыйгалар һәм күренешләр Аллаһының карары һәм Ихтыяры белән тәкъдир ителгән. Кешедә сайлау көче бар, шуның өчен ул Кыямәт көнендә хисап тотачак.

Кешенең сайлап алуы – гакыйдәнең иң катлаулы сорауларыннан. Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать мөселманнары берничә нигезгә таяналар: Аллаһы – Бердәнбер Яратучы, димәк, барлык вакыйгалар Аның тарафыннан барлыкка китерелгән. Әмма кешегә дини вазифалар йөкләнгән, димәк, кеше бу вазифалары өчен җаваплы. Аллаһы кешеләрне шул җаваплылык нигезендә хөкем итәчәк.

24. Дөньяда булган барлык хәлләр дә Аллаһы Теләге белән барлыкка килә. Аларның яхшылары белән Аллаһы канәгать, начарларыннан риза түгел.

Галәмдәге барлык вакыйгаларны Аллаһы бар иткән һәм, шуның өчен, барча нәрсә Аллаһы Тәгалә хөкеме астында, аның теләгенә каршы бер нәрсә дә барлыкка килә алмый, әмма кайбер вакыйгалар белән Аллаһы канәгать (мәсәлән, Аңа гыйбадәт кылу), кайберләреннән (мәсәлән, колның гөнаһ кылу теләге) – юк. Теләк – ул ризалык дигән сүз түгел.

25. Аллаһы колларының өстенә алар башкара алмый торган вазифалар йөкләми. Әгәр кеше намазны басып укый алмый икән, ул аны утырып башкара ала. Утырып та укый алмаса, намазны ятып укырга рөхсәт ителә.

Аллаһы – Гадел, шунлыктан, имам Әбү Мансур Әл-Матуриди фикеренчә, Аллаһы берничек тә Үзенең колларына көчләре җитмәгәнне йөкләми.

26. Кешегә хас барлык хис-кичерешләр Аллаһы тарафыннан барлыкка китерелгән.

Кешенең хис-кичерешләре – аның организмында барган биологик процесслардан, димәк, башка барлык процесслар кебек, алар да Аллаһы тарафыннан яратылганнар.

27. Аллаһы Үзе теләгән бәндәләрен туры юлга күндерә, теләгәннәрен туры юлдан тайпылдыра.

Туры юлга күндерүнең ике төре бар: беренчесе – пәйгамбәрләр, китаплар аша, икенчесе – турыдан-туры Аллаһы Тәгаләнең илһамы белән. Болар икесе дә – Аллаһы Тәгаләдән генә.

28. Аллаһы Үзенең бәндәләре өчен бернинди гамәл кылырга да бурычлы түгел, әмма Ул вәгъдә иткән һәр гамәл үтәләчәк, һәм Ул аны эшләргә бурычлы булган өчен түгел, ә Ул шулай теләгәне өчен.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать тарафдарлары фикеренчә, Аллаһы өчен мәҗбүри булган гамәл юк, Аллаһы, кемдер яисә нәрсәдер мәҗбүр иткәнгә түгел, бары Үзе теләгәнгә гамәлне барлыкка китерә. Әмма әгәр Аллаһы Үзенең китабында вәгъдә биргән икән, ул, һичшиксез, булачак, чөнки Аллаһы вәгъдәсен бозмый.

29. Кяферләрне һәм гөнаһлы мөэминнәрне кабер газабы көтә. Кабердә кешедән ике фәрештә сорау алачак. Алар кешедән Раббысы кем булуы, дине нинди булуы һәм пәйгамбәре кем булуы турында сораячак.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать тарафдарлары ышануларының берсе – кабердә соралуга ышану. Кабер газабы – кяферләр һәм гөнаһлы мөэминнәр өчен, ә тугры мөэминнәр өчен кабердә рәхәтлекләр вәгъдә ителгән. Кабер газабын инкяр итү – адашуның ачык билгесе.

30. Кыямәт көнендә кешеләр терелтеләчәк һәм матди тәннәре белән Аллаһы хозурына китереләчәк. Аларның гамәлләре Мизанда үлчәнәчәк. Кешеләр Сират күпере аша узачаклар, һәм, нәтиҗәдә, кяферләрне мәңгелек җәһәннәм, ә мөэминнәрне мәңгелек җәннәт көтә. Гөнаһлы мөэминнәрнең бер өлеше җәһәннәмгә керәчәк һәм, гөнаһлары юылып, җәннәткә күчереләчәк.

Мөселманнар җисми кубарылуга һәм кылган гамәлләр өчен җавап бирелүгә ышаналар. Җәннәттә һәм җәһәннәмдә дә рухи ләззәт яки рухи газап түгел, ә җисми әҗер биреләчәк, ягъни тән аларны тоячак.

(Дәвамы киләсе санда)

■ Мөфти **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**



Фото: shutterstock.com

# Татар имамының Госманлы империясе ордены белән бүләкләнүе

***Газетаның үткән санындагы мәкаләне без ишан Хәсән улы Нургали Әл-Буави турында бәян итүгә багышлаган идек. Ә хәзер Нургали хәзрәтнең Госманлы империясенә сәфәр кылуына тукталыйк.***

1906 елда Хәсән улы Нургали, улы Гыясетдинны «Даруль-Мугаллимин»га укырга бирү нияте белән, Стамбул шәһәренә килә. Госманлы империясендә укытучылар әзерли торган мәктәп шулай дип аталган була. Болардан тыш Нургали хәзрәт Бурса шәһәрендәге җылы су чыганакларына барырга теләгән.

Стамбулда ул төрле мәчетләрдә, мавзолейларда, музейларда, мәдрәсәләрдә һәм суфилар торган урыннарда булган. Шулай ук җирле китапханәләрдә үзенең китапларын калдырган. Нургали хәзрәт Госманлы империясенең танылган дин эшлеклеләре белән очраша алган. Алар арасында Ислам шәехе Җәмәлетдин әфәнде, Әбү Әл-Худа әфәнде, шәех Ибраһим Зариф һәм башкалар да булган.

Стамбулның суфичылар торган җирләрендә ул зикер һәм хәтем мәҗлесләрендә, шулай ук мәчетләрдә вәгазьләр һәм нәсыйхәтләр сөйләнгән урыннарда катнашкан. Шул вакыт эчендә ул Госманлы империясенең Ислам шәехләренә дин мәсьәләсенә кагылышлы фәтваларын биргән. Мәсәлән, ирнең хатыныннан аерым торуы, һавадагы айны күзәтеп ай башын билгеләү һ.б.

Укытучының хатирәләреннән шунысы билгеле: Госманлы империясендәге кайбер гореф-гадәтләр аның өчен сәер булган. Мәсәлән, хәтем, ягъни кешеләрнең булешеп тулаем Коръәни Кәримне укып чыгулары һәм аннары бергәләп дога кылулары; мәхия, бу – мөселман бәйрәмнәре, бигрәктә Рамазан ае вакытында, ике мәчет манаралары арасын янып торган фонарьләр ярдәмендә язулар һәм рәсемнәр белән бизәү.


1906 елның 1 нче сентябрендә ул солтан Габделхәмид IIнең хакимияткә килүенең 30-еллыгын билгеләп үтү тантанасының шаһиты була.

Бурсада Нургали хәзрәт җылы су чыганакларында була, истәлекле урыннарны күрә, Дагыстан шәехе Мөхәммәд Элмәле һәм шәех Шәрәфетдин белән очраша.

Әмма аның сәфәрендәге иң әһәмиятле вакыйга – ул солтан Габделхәмид II белән очрашу булгандыр. Солтанның хәлиф, ягъни барлык мөселманнарның дин башлыгы булуын да истән чыгармаска кирәк.

Ике ай чамасы Нургали хәзрәт төрек патшасының сараенда яши һәм солтан тарафыннан игътибарга һәм мактауга лаек була. Бу вакыйга Рамазан аена туры килә. Нургали хәзрәт солтан Габделхәмид IIгә бик нык якыная, хәтта алар бергәләп ифтар кылалар, тәравих намазларын укыйлар. Сарайдагы тәртип, әдәп буенча, хәзрәт солтан белән очрашкач, аның кулын үбә торган була. Хәтта алар берьюлы дусларча кочаклашалар да.

Ихтирам йөзеннән 1906 елның 1 нче ноябрендә солтан (рәсми указ нигезендә) Нургали хәзрәтне I нче дәрәҗәдәге Госмания ордены белән бүләкли. Бу орден белән, Госманлы империясе алдында күркәткән хезмәтләре өчен, гражданлык хезмәткәрләрен, хәрби бүлек башлыкларын бүләкли торган булганнар. I нче дәрәҗәдәге орден кайвакытларда бриллиант белән бизәлгән. Шунысы игътибарга лаек, Госманлы империясенең ордены белән барлыгы иллеләп кеше бүләкләнгән.




*Хәсән улы Нургали хәзрәтнең истәлекләре.*
Фотоның чыганагы: ikrakitap.com



*I нче дәрәҗәдәге Госмания ордены лентасы*
wikipedia.org сайтыннан

Нургали хәзрәт күп тапкырлар солтанны җомга көн сәламләү һәм рәсми аудиенция (югары дәрәҗәдәге кешенең рәсми рәвештә кабул ителүе) чараларында катнашкан. Нургали хәзрәтнең мемуарлары ярдәмендә Габделхәмид IIнең кичләре һәм төннәре ничек узганын да беләбез. Солтанның әүлия булуы һәм шул вакытның суфие булуы хакында билгеле. Нургали хәзрәт бу фикерләрне раслап, солтанга илһам (Аллаһыдан бирелгән гыйлем) һәм кәшеф (калебнең күп әйберләрне аңлавы) кебек үзенчәлекләр бирелүе хакында билгеләп үтә. Хәзрәт солтанның сарай китапханәсенә кереп, сирәк очрый торган хезмәтләр белән танныша алган.

Хәсән улы Нургали өчен иң зур бүләк – ул солтанның аны улы белән хаҗга җибәрергә карар кылуы. Алар хаҗга Сюррейск полкы белән бергә кузгалганнар. Бу сәяхәт солтаннар тарафыннан әзерләнеп, Стамбулдан Мәккәгә һәм Мәдинәгә кадәр әзерләнгән махсус сакчылар белән озата барылган. Сюррейск полкы Хиҗазга кадәр атларда, качырларда һәм дөяләрдә изге җирләр өчен мөселманнар тарафыннан җыелган кыйммәтле әйберләрне һәм һәм акчалата ярдәмне илтеп җиткерергә тиеш булган. Димәшкъка килеп җиткәннән соң, Нургали хәзрәт улы белән Бәйрутка юнәлә, ә аннан диңгез аша Хиҗазга ирешә.

Үзенең юлында алар төрле мәчетләргә, мәдрәсәләргә, мәктәпләргә, мавзолейларга, китапханәләргә керә. Шулай ук алар җирле түрәләрнең һәм галимнәрнең мәҗлесләрендә катнаша. Галимнәр белән очрашканда Нургали хәзрәт төрле сораулар буенча фәтваларын да әйтә.

Күпмедер вакыттан соң Нургали хәзрәт туган ягына Буага кайта һәм «Нурия» мәдрәсәсен җитәкли башлый. Нәтиҗәдә ул ике китап нәшер итә. Анда Госманлы империясенә сәяхәте тасвирланган була: «Әл-гәвәтыйф әл-хәмидия фиссәяхәти нурия» («Нурлы сәяхәттән туган рәхмәт хисләре») китабы 1907 елда (гарәп телендә) Казанда басыла. Бу китапны Нургали хәзрәт төрек солтанына рәхмәт буларак әзерли һәм анда үзенең сәяхәтен бәян итә.

**Дамир ГАЙНЕТДИНОВ**
язмасы, islam-today.ru
сайтыннан тәрҗемә

# Гыйбадәт өчен вакыт табу

Шәкыйкъ Әл-Бәлхый рахимәһуллаһи рухи яктан камилләшү һәм гыйлем алу юлына басканчы һәрдаим сәүдә эшләре белән сәфәр кыла иде.

Берьюлы шундый эшлекле сәфәре вакытында насара хакиме аннан юлда күпме вакыт үткәргәнлеген сорады. Шәкыйкъ Әл-Бәлхый: «Мин монда өч айда килеп җитәм, өч ай кирәкле товарларны туплыйм, тагын өч аем туган ягыма кайту вакытын тәшкил итә һәм алып кайтканнарымны сатып бетерер өчен миңа өч ай вакыт кирәк», – дип әйтә.

Хаким болай дип әйткән:

– Әгәр синең сәфәрең һәм сәүдәң тулы бер елны тәшкил итсә, кайчан соң син Раббыңа гыйбадәт кыласың?

Бу сүзләр Шәкыйкъ Әл-Бәлхыйга бик нык тәэсир ясый. Ул сәүдә эшләрен калдырып, үзен гыйбадәткә багышлый.

**Нәсыйхәт:**

Кеше нинди генә шартларда булса да,ниләр белән генә шөгыльләнсә дә, бу аның гыйбадәт кылуына зыян китерергә тиеш түгел. Ул Аллаһының әмерләренә игътибарсыз калмаска тиеш. Эшнең гыйбадәткә комачау итүе дөрес түгел. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә эштә булучы кешегә гыйбадәт кылмаса да ярый, дигән сүзләр әйтмәгән. Гыйбадәт кылу һәркем өчен фарыз (үтәлүе мәҗбүри булган) гамәл.

# Берәү дә күрмәгән урын

Аллаһының дусты булган бер кешенең укучылары бар иде. Әмма ул араларыннан берсен, башкаларга караганда, аеруча нык яратты һәм аңа күбрәк игътибар бирде. Калган укучылары:

– Нигә сез аңа шулхәтле игътибар бирәсез? Без дә сезнең укучыларыгыз, – дигәннәр. Укытучы:

– Мин сезгә нигә аңа күбрәк игътибар бирүемне аңлатырмын, – дип җавап бирә.

Шуннан соң һәрбер укучысына берәр кош биреп, берәү дә күрми торган урында аны чалырга куша. Укучылар төрлесе төрле якка таралышып, күпмедер вакыттан соң чалынган кошлар белән кайтып керәләр. Әмма шәехтән күбрәк игътибар алган укучы тере кош белән кайта.

Шәех әлеге укучысыннан:

– Нигә кошны чалмадың? – дип сорый.

Ул:

– Сез кошны берәү дә күрми торган җирдә чалырга куштыгыз, әмма мин берәү дә күрми торган урынны белмим, – дип җавап бирә.

Моны ишеткән шәех үзенең укучыларына борылып:

– Менә шуның өчен мин аны башкалардан күбрәк яратам да инде, – дип әйтә.

# Гайбәт тарату

Бер кеше, Хәсән Әл-Басри рахимәһуллаһи янына килеп, болай дип әйткән: «Фәлән кеше сезнең аркагыздан сөйләде». Хәсән Әл-Басри: «Кайчан?» – дип сораган. Теге кеше: «Фәлән көнне», – дигән. Хәсән Әл-Басри: «Син аны кайда күрдең?» – дип сораган. Ул: «Аның өендә», – дигән. Хәсән Әл-Басри: «Ул өендә нишли иде?» – дип сораган. Ул: «Ул кунак җыеп, аларны сыйлады», – дигән. Хәсән Әл-Басри: «Ул нинди ризыклар әзерләгән иде?» – дигән. Ул: «Бик күп. Барлыгы сигез төрле ризык бар иде», – дигән. Бу сүзләргә җавап итеп, Хәсән Әл-Басри рахимәһуллаһи: «Их син! Синең ашказаның сигез төрле ризыкны сыйдырган, әмма минем хакта әйтелгән бер сүзне сыйдырмаган. Кит бар моннан, фасикъ», – дигән.

**Нәсыйхәт**:

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

**«Ий иман китерүчеләр! Әгәр [гөнаһтан сакланмаган, шуңа ялган сөйләмәячәгенә ышаныч булмаган] фасикъ бер кеше сезгә [мөһим] хәбәр китерсә, [аның асылын] тикшереп белегез, югыйсә, [гаепсез] кешеләргә белмичә, зыян китерерсез дә, шуннан [гаепсез булулары ачыкланганнан] соң [аларга] кылган нәрсәгез аркасында үкенерсез».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:6

# Бер хөрмә җимеше белән тулган үлчәү тәлинкәсе

Давыд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән Кыямәт көнендә кешеләрнең гамәлләре салыначак үлчәүне күрсәтүен сораган. Үлчәүнең һәрбер тәлинкәсе көнчыгыштан көнбатышка хәтле булган араны алып торган. Давыд галәйһиссәлам аларны күреп, аңын югалтып егылган. Һәм аңына килгәч:

– Йә Раббым! Бу тәлинкәләрне изге гамәлләр белән тутырырга кемнең көченнән килер? – дип сораган.

Аллаһы Тәгалә:

– Йә Давыд! Әгәр Мин берәр колымнан риза булсам, бу тәлинкәне садака итеп биргән бер хөрмә җимеше белән тутырачакмын», – дип җавап биргән.

**Нәсыйхәт:**

Мизан – Кыямәт көнендә кешеләрнең яхшы гамәлләре һәм гөнаһлары салына торган үлчәүнең исеме ул. Бу үлчәүләрнең нинди формада булуларын, кыяфәтләрен һәм үлчәүнең ни рәвештә башкарылачагын Аллаһы гына белә. Безгә үлчәүләрнең булуына, Аллаһыга тапшырылып, гамәлләребезнең үлчәнүенә ныклап ышанырга кирәк.

Имам Раббани болай дип әйткән: «Гамәлләр өчен хисап тоту, үлчәүләрнең урнаштырылуы, кешеләргә гамәлләренең китабы бирелү – болар барысы да хакыйкать булып тора» (Имам Раббани, Мәктүбәт, 3/17).

■ **«Рухуль Бәйан»** китабыннан



Фото: shutterstock.com

# Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе

***Гайшә радыяллаһу ганһә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять иткән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мин җәннәткә кердем һәм анда берәүнең Коръән укыганын ишеттем. Бу Коръән укучының кем булуын сорагач, миңа җавап итеп: «Коръәнне укучы Харисә бине Ногъман! Тәкъва булучыларның халәте әнә шундый!» – дип әйттеләр».***


Фото: shutterstock.com

### Ислам динен кабул итүе

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе үзенең әнисен бик хөрмәт иткән. Бервакыт аңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәләмнең дәгъваты турында хәбәр ирешкән. Ул бу хакта күбрәк белергә теләгән. Аңа Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәдинәдә Мосгаб бине Гомәер исемле йомышчысы барлыгы һәм аның башкаларны Коръән укырга өйрәтүе һәм имам булып алар белән намаз гыйбадәтен үтәве хакында әйткәннәр. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе Мосгаб бине Гомәер янына барган. Мосгаб бине Гомәер кыскача аңа Ислам дине хакында сөйләгән. Шуннан соң Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе Ислам динен кабул итүе хакында хәбәр иткән.

Ислам динен кабул иткәч, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе потка табынучы әнисе хакында бик борчылган. Аллаһы Тәгалә аның да йөрәгенә дөрес юлны күрсәтсен, дип Раббысына догалар кылган. Өенә кайткач, әнисенә Ислам динен кабул итүе хакында хәбәр иткән һәм әнисе дә: «Мин дә үземнең Ислам динен кабул итүем хакында игълан итәм», дип әйткән.

Мәдинә шәһәрендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәләмнең һиҗрәте хакында хәбәр таралгач, мөселманнар моңа бик шатланганнар. Бу хәбәргә бигрәк тә Харисә бине Ногъман шатланган. Көн саен мөэминнәр шәһәр капкасы янына чыгып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне көткәннәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллә‍м һәм аның сәхабәләрен каршы алучылар арасында иң беренчеләрдән Харисә бине Ногъман булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәһәргә дөягә утырып кергән. Һәркем Аллаһының Расүле нәкъ менә аның йорты тирәсендә туктавын теләп, дөянең тезгененнән тарткан. Дөя исә Әбү Әюб Әл-Әнсари йорты янында туктаган. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе моңа бик шатланган, чөнки үзе дә, Әбү Әюб Әл-Әнсари кебек, нәҗҗар кавеменнән булган һәм аның белән күрше булып яшәгән.

### Пәйгамбәребезнең күршесе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсе һәм туганнары Мәккәдән Мәдинәгә күченгәч, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе аларны үз өендә кунак иткән. Барлык кирәк-нәрсәләр белән тәэмин итәргә тырышкан һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәм итә алуына бик шатланган. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ихластан яраткан, хөрмәт иткән һәм аның өчен һәрнәрсәне дә эшләргә әзер торган.

Сәхабәләр Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһене Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күршесе дип атаганнар, чөнки аның йорты Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчетенә якын булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә йорт кирәк булганда, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе ике дә уйламый аңа үзе яшәгән йортны тәкъдим иткән, ә үзе өчен яңа йорт төзегән.

Һиҗрәтнең икенче елында Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Фатыйма исемле кызына өйләнгән. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу яшь гаиләнең үзенең янәшәсендә генә, күршеләр булып яшәүләрен теләгән. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе бу хакта хәбәрне ишеткәч үк Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып: «Йә, Аллаһының Расүле, мин Бәни Нәҗҗар кавеменең иң ышанычлы йортын, ягъни үз йортымны аларның карамагына тапшырам. Минем барлык малым Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аның Расүленеке. Аллаһы белән ант итәм, йә Аллаһының Расүле, миңа бирүеңә караганда, миннән алуың минем өчен хәерлерәк», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең ихласлыгына ышанган һәм аның тәкъдимен кабул иткән. Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһе һәм хәзрәти Фатыйма үзләренә йорт төзегәнче Харисә бине Ногъман йортында яшәгәннәр.

### Күркәм сыйфатлары

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тугрылыгы, хөрмәте моның белән генә чикләнмәгән. Башка мөселманнар белән бергә ул да Ислам дине өчен күп тырышлык куйган. Һәрвакытта да Аллаһының Расүле янәшәсендә булырга тырышкан, аны саклаган. Ислам дине өчен бар булганын фида кылган. Кылган һәрбер гамәлен Коръәни Кәримнең түбәндәге сүрәсенә таянып башкарган:

**«Әйт: «Әгәр сезнең аталарыгыз, улларыгыз, кардәшләрегез, хатыннарыгыз, гаиләләрегез, кәсеп иткән малларыгыз, торгынлыкка төшүеннән курыккан сәүдәгез һәм күңелегезгә якын торакларыгыз сезгә Аллаһыдан, Аның Расүленнән [һиҗрәт] һәм Аның юлында тырышлык кылудан сөеклерәк икән, Аллаһы [дөньяда да, Ахирәттә дә сезнең белән бәйле газап] әмерен китергәнне көтегез. Аллаһы [дошманнары белән дус булып, әмереннән чыккан] фасикълар кавемен [ике җиһанда да морадларына ирештерми һәм туры юлны табарга] һидаять итми».**

«Әт-Тәүбә», 9:24

Харисә бине Ногъман өчен бу гадәти сүзләр генә булмаган. Ул һәрвакыт шушы сүзләрне исендә тотып, һәр гамәлен Аллаһы ризалыгы өчен башкарган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң да, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе динебез юлында тырышлыкларын киметмәгән. Башкалардан юмартлыгы, батырлыгы белән аерылып торган. Аның кебекләр хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Моңа кадәр [Мәдинә диган] йортта яшәгән һәм күңелләренә иманны салган кешеләр үзләренә [Мәккәдән] һиҗрәт кылган кешеләрне [җаннарытәннәре белән] сөяләр, аларга [мөһаҗирләргә] бирелгән [ганимәт малы кебек] нәрсәләрдән берни‍нди көнләшү хис итмиләр. Үзләрендә ихтыяҗ булса да, [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] аларны үзләреннән өстен күрәләр. Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана [һәм Аллаһы юлында сарыф итә], шулар – уңышка [һәм котылуга] ирешүчеләр».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:9

### Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең вафаты

Гомеренең азагына Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе сукыр калган. Бу халәтенә разый булып, соңгы көннәренә кадәр намазларын мәчеткә йөреп башкарган.

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе 51 нче һиҗри елда вафат булган.

■ Сәхифәне **Лилия ХӘЛӘФЕТДИНОВА** әзерләде

# Шигъри сабаклар

***Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшин дини журналист һәм язучы буларак билгеле. Аның динебез кыйммәтләренә, яшәешебезнең төп максатына, әдәп-әхлак вә тәрбия мәсьәләләренә багышланган хикәяләре һәм публицистик язмалары милләттәшләребезгә инде яхшы таныш, ә бу юлы исә Ришат хәзрәт редакциягә шигъри вәгазь формасындагы дини әчтәлекле шигырьләрен юллаган. Шуларны укучыларга тәкъдим итеп, мөхтәрәм имамнар һәм абыстайлар әлеге шигъри вәгазьләрне мәхәлләдәшләренә ирештерерләр дигән өметтә калабыз.***

Редакциядән

## Гомер елгасы

*Еллар, көннәр сулар кебек ага,*
*Талгын ага гомер елгасы.*
*Үз юлыннан киләчәккә таба*
*Тагын күпме аңа агасы?*

*Белмибез шул күпме тәкъдирләнгән,*
*Агым безне кая илткәнен...*
*Беләбез тик алда һәммәбезне*
*Иксез-чиксез дәрья көткәнен.*

*Безнең теләк-уйга карамастан,*
*Агым мәңгелеккә юнәлә...*
*Шулай алдан билгеләнгән тәкъдир*
*Аллаһ язган белән үтәлә.*

*Елга ага... Кайчак тын дулкыннар*
*Хәвефләнеп алга ашкына.*
*Кайчак ярга бәргәләнеп ала,*
*Килеп чыкса киртә каршыга.*

*Кайвакытта ачы күз яшьләре*
*Хыял ярларына түгелә.*
*Ләкин тукталырга һич ярамый –*
*Агым янә алга юнәлә...*

*Бу елганың ярларында күргән*
*Төрле вәсвәсәгә кызыгып,*
*Без саташсак – Аллаһ гел коткарды,*
*Дөрес юнәлештә агызып.*

*Ий Раббыбыз! Инде ничә тапкыр*
*Мәрхәмәтең илә коткардың:*
*Төшеп китә язгач зур упкынга,*
*Туры юлда безне калдырдың.*

*Елгабызда Иман көймә булсын,*
*Тәкъвалык белән барыйк ишеп,*
*Ә азакта шатланырга язсын*
*Кәүсәр елгасына ирешеп...*

## Авырып китте кардәшем...

*Авырып китте кардәшем,*
*Шуңа читкә куеп бар эшем,*
*Ашкындым тизрәк янына –*
*Тынгы салам диеп җанына.*
*Хәбәре бик шомлы булды,*
*Чарасыздан күңелем тулды...*
*Дустымның хәле авыррак:*
*Яман шеш таптылар, диде... рак...*
*Тиз килеп җиттем өенә.*
*Моңайды ул кайгы көенә:*
*– Шундый хәл... – диде аптырап,*
*– Көтмәгәндә булдым бит харап...*
*Шушылай гыйбрәт алганчы,*
*Уйлап карамадым моңарчы:*
*Яшәрмен озак янәсе,*
*Ә янымда – үлем шаүләсе...*
*... Дәшмичә утырдым әүвәл.*
*Дөрестән дә – шактый авыр хәл...*
*Күзләрендә тик бер сорау:*
*– Нигә миңа булды бу сынау?!*
*Нигә мин? Мин яшь бит әле!*
*Тормышның кызыклы һәр мәле...*
*Моңарчы яшәдем рәхәт,*
*Каян килеп чыкты бу зәхмәт?*
*... Карашым төбәп идәнгә,*
*Әйттем: Аллаһ безне сөйгәнгә*
*Саулыкны бирә һәм чирне –*
*Насыйп итеп тик хәерлене.*
*Аллаһның хөкеме кырыс,*
*Тик тәкъдиргә ышану – фарыз!*
*Раббыбыз кадир, шәфкатьле,*
*Ни бирсә дә – бул итагатьле.*
*Ирештеме сиңа зәхмәт –*
*Бел: монда ниндидер бар хикмәт.*
*Туймасаң да җан рәхәте,*
*Авыру – Аллаһның рәхмәте.*
*Моңарчы ваемсыз булдың,*
*Онытылып, тик дөнья кудың,*
*Авыргач – исеңә төшә*
*Бөек Раббың... Ул сиңа дәшә:*
*– Күп чаптың инде, әй колым!*
*Үз-үзеңә кылдың күп золым:*
*Раббыңны искә алмыйча,*
*Күңелеңне дингә салмыйча,*
*Туры юлдан читкә китеп,*
*Кыйммәт вакытны әрәм итеп...*
*Бу дөнья – вакытлы торак,*
*Яшәп булмый монда бик озак,*
*Иң күбе – сиксән-туксан ел,*
*Соңыннан исә – мәңгелек... Бел!*
*Бу тормыш кайчандыр бетәр,*
*Һәммәбез ахирәткә китәр.*
*Шунысы зур әһәмият –*
*Яшәүнең максаты, төп нният...*
*Аллаһның бәндәсе булсаң,*
*Тормышның максатын аңласаң,*
*Күпме гомер бирелсә дә,*
*Бүген үлсәң дә, терелсәң дә,*
*Син инде бәхетле кеше –*
*Хәерлегә була һәр эшең!*
*«Нигә мин, ник миңа?» – дисең,*
*Шушы хәлгә китмәсен исең!*
*Якынаерга Раббыңа*
*Ярдәм итә авыру... Шуңа*
*Кайгырма китте дип саулык,*
*Гыйбадәтсез ул – шикле байлык.*
*Аллаһның рәхмәте олы,*
*Тик Аның ихласлы бул колы.*
*Иң зур байлык – ихлас иман,*
*Аллаһның ярдәменә инан!*
*Биргәненә шөкер итсәң,*
*Ризалыгын алып яшәсәң,*
*Ярдәменнән Ул ташламас,*
*Авыр хәлдә сине калдырмас...*
*Ул моны бит вәгъдә итте,*
*Бер әйтүе дә безгә җитте.*
*Аңа тәвәккәлләп яшә,*
*Якын дус-туганнар – янәшә!*
*Шунысы да мөһим, кардәш:*
*Раббыңа син дога кылып дәш!*
*Саулык сорарга бар хакың,*
*Бел: Аллаһ һәрвакыт бик якын!*
*Теләсә – шифасын бирер,*
*Авыру дәвасын белдерер.*
*Юк икән – моны кабул ит,*
*Бу хөкемгә риза булып кит...*
*Аллаһка итагать итсәң,*
*Кабул итеп иманлы китсәң,*
*Кыены дөньяда калыр,*
*Ахирәттә әҗере булыр.*
*Барысын да була бирсәң,*
*Шул әҗернең кыйммәтен белсәң!*
*...Шулай да, син әле исән*
*Һәм нишлим икән хәзер дисәң,*
*Хаталарың барлап бөтен,*
*Аллаһыдан син гафу үтен.*
*Кем хакын боздың – бәхилләш,*
*Һәрберсе белән күреш, сөйләш,*
*Мөмкинлек булганда төзәт*
*Башкалар белән мөнәсәбәт.*
*Тәүбәгә кил. Кичер. Аңла...*
*Күңелеңне өметкә багла,*
*Ләкин бу дөньяга түгел –*
*Ахирәткә ашкынсын күңел!*
*Хак максат, чын бәхет анда –*
*Фәкать мәңгелек тормышында!*
*Иманлы кешене көтә*
*Искиткеч яшәеш җәннәттә...*
*Раббыңа син ихлас ышан*
*Һәм зыян салмасын шайтан,*
*Нәфеснең кылына тиеп,*
*Гадел түгел бу хөкем, диеп.*
*Барысы алдан язылган,*
*Шайтан сүзе – вәсвәсә, ялган!*
*Шушы хәл – бары тик сынау*
*Тугрылыкка... Шуңа – бул уяу:*
*Раббыңа тугры булып кал,*
*Бу дөньяны корбан итеп «чал»!*
*Барысын Аллаһ хәл итә,*
*Бәхетле булырга Ул җитә...*
*...Күтәрде башын кардәшем*
*Һәм елмаеп сөртте күз яшен,*
*– Мең шөкер Раббыма! – диде,*
*– Мин бүтән кайгырмамдыр инде,*
*Аллаһым бар икән минем,*
*Туры юлны күрсәткән динем,*
*Аллаһтан ихлас сорармын,*
*Син әйткәнчә, дога кылырмын...*
*Ахыргы нәтиҗә – Аннан,*
*Мәрхәмәтле, юмарт Раббымнан.*
*Ни булса да – кабул итәм...*
*Ә сине – иртәгә дә көтәм.*
*Килмәсәң – шалтырат, эндәш!*
*Ярый син бар әле, әй кардәш!*
*Зур рәхмәт: килеп яныма,*
*Нурлы бүләк салдың җаныма...*
*Аллаһның рәхмәте яусын,*
*Дуслыгыбыз мәңгелек булсын.*

## Яулык

*Яулык ябу мөслимәләр өчен фарыз,*
*Фарыз, димәк, бөек Аллаһ шулай*
*кушкан.*
*Тыйнак, тыныч, имин яшәр өчен яулык*
*Хатын-кызга гомер буе бик булышкан.*

*Абыстайлар шушы хакта болай диләр:*
*«Яулык – ул мөслимә өчен калкан*
*кебек,*
*Ул шәһвәтле, азгын карашлардан*
*саклый,*
*Шуңа күрә без яланбаш һич йөрмәдек!».*

*Кызлар яулык япса – гүзәл, нурлы була!*
*Егетләрнең начарлары моны күрми,*
*Тәртиплеләр исә «Субханәллаһ!» диеп,*
*Шундый кызга никахланам дип ниятли.*

*Яулык саклый, яулык ул бәхетле итә,*
*Әй мөслимә, син яулыктан аерылма!*
*Гыйбадәттә булып, баштан гына*
*түгел –*
*Күңел яулыгыңны да син салма.*

## Кайту

*Зина кылам диеп өйдән чыккан егет,*
*Ап-ак эчке кием сайлап кигән...*
*Күңеленнән иман качкан мәлдә*
*Ул шайтанга: «Әйе, ярар», – дигән.*
*И шатланды мәлгунь, «җиңдем» диеп*
*моны*
*Һәм үзенә вәгъдә бирдертеп,*
*Аның күңелендәге аклыкны*
*Арт ягына куйды кидертеп.*
*И рәнҗеде, и хурланды мескен аклык!*
*Нәүмиз калып, үксеп елады...*
*Егет исә моңа төшенмичә,*
*Янә шайтан юлын сайлады.*
*«Бу мәсхәрә хәлгә ничек төштең соң*
*син?*
*Миңа һаман пычрак атасың.*
*Син оныттыңмыни, бәндә, тиздән*
*Ахирәткә кире кайтасын?*
*Дәрт-теләкне басу өчен синең Раббың*
*Рөхсәт иткән хәләл юлны сайлап,*
*Мине рәнҗетмичә гамәл кылып,*
*Була иде тормышыңны җайлап!»*
*Шулай дия-дия һай сукранды аклык,*
*Хыялланып җанга кайтырга.*
*Ә хуҗасы... артын өстен күреп,*
*Нәфсен әйләндерде батырга.*
*Гает көнне дусты кыстап «әйдә»*
*дигәч,*
*Килде егет Җәмигъ мәчеткә,*
*Әй утырды ул кыбырсыкланып,*
*Килеп капканмыни читлеккә...*
*Вәгазь бик үтемле булды. Имам әйтте:*
*«Зина – ӘҖӘТ ул, кем аны алыр,*
*Соңрак бу әҗәтне Аллаһыга*
*Үз туганы белән кайтарыр.*
*Бу турыда ышанычлы бер хәдистә*
*Аңлатыла – җәза шул булыр:*
*Килер вакыт – зина кылучының*
*Балаларын кемдер аздырыр»...*
*Уйга батты егет. Кайтыр юлын*
*күрми...*
*Билә алды җанын зур хәсрәт!*
*«Тик үкенсәң – Аллаһ гафу итә» –*
*Шулай диде кебек бу хәзрәт...*
*Кинәт туктап калды егет һәм*
*тезләнде,*
*Ихлас тәүбә аны елатты...*
*«Кичер, Раббым!» – диде һәм шул мәлдә*
*Аклык күңеленә кире кайтты.*

■ **Ришат хәзрәт КУРАМШИН,** Кукмара мәдрәсәсе мөдире



Фото: publicdomainpictures.net

12+

### ДҮШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:0 Намазга өйрәник
08:20 Татарлар тарихы
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 Бер мәчет тарихы
09:30 Һөнәрләр
09:45 «Таз малай» мультфильмы
10:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:35 Җан авазы
10:40 Тәмле булсын
11:00 Хәзинә
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:30 «В тени милости Аллаха»
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55 «Малец удалец» мультфильмы
13:10 «Маленькие взрослые»
13:15 «Голос разума»
13:45 «Такой татарский русский»
13:50 «Золотой век исламской цивилизации»
14:00 «Счастье без границ»
14:10 «История Ислама в России» Марат Сәфәров белән
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 Нәфис сериал
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Намазга өйрәник
17:20 Татарлар тарихы
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 Бер мәчет тарихы
18:30 Һөнәрләр
18:45 «Таз малай» мультфильмы
19:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:35 Җан авазы
19:40 Тәмле булсын
20:00 Хәзинә
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:20 «История Ислама в России» Марат Сәфәров белән
21:40 Фәнни-танып-белү фильмы
22:10 Нәфис сериал
23:10 «В тени милости Аллаха»
23:25 «Маленькие взрослые»
23:30 «Голос разума»
00:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
00:25 «Такой татарский русский»
00:30 «Золотой век исламской цивилизации»
00:40 «Хикмәтле хикәяләр»
00:55 Коръәни Кәрим укылышы

### СИШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 Тәмле булсын
09:25 Намазга өйрәник
09:45 Гаилә дәресләре
10:15 Хикмәтле хикәяләр
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 Бер хәдис – бер җавап
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 Җан авазы
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Момент истины» Гали Абдусалимов белән
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55 «Маленькие взрослые»
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 Счастье без границ
13:30 «Золотой век исламской цивилизации»
13:40 Минбар истории
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 Нәфис сериал
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30«Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 Тәмле булсын
18:25 Намазга өйрәник
18:45 Гаилә дәресләре
19:15 Хикмәтле хикәяләр
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 Бер хәдис – бер җавап
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 Җан авазы
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:20 «Маленькие взрослые»
21:25 «Минбар истории»
21:55 Фәнни-танып-белү фильмы
22:25 Нәфис сериал
23:25 «Такой татарский русский»
23:30 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
23:50 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
00:10 Халяль-лайфстайл
00:30 Есть вопрос – есть хадис
00:50 «Счастье без границ»
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ПӘНҖЕШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 Тәмле булсын
09:25 Намазга өйрәник
09:45 Гаилә дәресләре
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 «Бер хәдис – бер җавап»
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 Җан авазы
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Момент истины» Гали Абдусалимов белән
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55 «Маленькие взрослые»
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 «Счастье без границ»
13:30 «Золотой век исламской цивилизации»
13:40 «Минбар истории»
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 Нәфис сериал
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 Тәмле булсын
18:25 Намазга өйрәник
18:45 Гаилә дәресләре
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 «Бер хәдис – бер җавап»
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 Җан авазы
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:20 «Маленькие взрослые»
21:25 «Минбар истории»
21:55 Фәнни-танып-белү фильмы
22:25 Нәфис сериал
23:25 «Такой татарский русский»
23:30 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
23:50 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
00:10 Халяль-лайфстайл
00:30 Есть вопрос – есть хадис
00:50 «Счастье без границ»
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ҖОМГА, ЯКШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 Татарлар тарихы
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 Бер мәчет тарихы
09:30 Һөнәрләр
09:45 «Таз малай» мультфильмы
10:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:35 Җан авазы
10:40 Тәмле булсын
11:00 Онлайн-мәдрәсә
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:30 «В тени милости Аллаха»
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55 «Малец удалец» мультфильмы
13:10 «Маленькие взрослые»
13:15 «Голос разума»
13:45 «Такой татарский русский»
13:50 «Золотой век исламской цивилизации»
14:00 «Счастье без границ»
14:10 «История Ислама в России» Марат Сәфәров белән
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 Нәфис сериал
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 Татарлар тарихы
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 Бер мәчет тарихы
18:30 Һөнәрләр
18:45 «Таз малай» мультфильмы
19:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:35 Җан авазы
19:40 Тәмле булсын
20:00 Онлайн-мәдрәсә
20:30 Минбар
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:20 «История Ислама в России» Марат Сәфәров белән
21:40 Фәнни-танып-белү фильмы
22:10 Нәфис сериал
23:10 «В тени милости Аллаха»
23:25 «Маленькие взрослые»
23:30 «Голос разума»
00:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
00:25 «Такой татарский русский»
00:30 «Золотой век исламской цивилизации»
00:40 «Хикмәтле хикәяләр»
00:55 Коръәни Кәрим укылышы

### ШИМБӘ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 Тәмле булсын
09:25 Намазга өйрәник
09:45 Гаилә дәресләре
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 Бер хәдис – бер җавап
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 Җан авазы
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Момент истины» Гали Абдусалимов белән
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55 «Маленькие взрослые»
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 «Счастье без границ»
13:30 «Золотой век исламской цивилизации»
13:40 «Минбар истории»
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 Нәфис сериал
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 Тәмле булсын
18:25 Намазга өйрәник
18:45 Гаилә дәресләре
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 Бер хәдис – бер җавап
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 Җан авазы
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:20 «Маленькие взрослые»
21:25 «Минбар истории»
21:55 Фәнни-танып-белү фильмы
22:25 Нәфис сериал
23:25 «Такой татарский русский»
23:30 Уроки тафсира (Камил Сәмигуллин)
23:50 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
00:10 Халяль-лайфстайл
00:30 Есть вопрос – есть хадис
00:50 «Счастье без границ»
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

# Казан өчен октябрь аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Зәүвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01.10.2021 | Җом | 03:41 | 04:16 | 05:46 | 11:33 | 12:00 | 15:18 | 17:18 | 19:00 |
| 02.10.2021 | Шим | 03:43 | 04:18 | 05:48 | 11:32 | 12:00 | 15:16 | 17:16 | 18:57 |
| 03.10.2021 | Якш | 03:45 | 04:20 | 05:50 | 11:32 | 12:00 | 15:14 | 17:13 | 18:55 |
| 04.10.2021 | Дүш | 03:48 | 04:22 | 05:52 | 11:32 | 12:00 | 15:11 | 17:11 | 18:52 |
| 05.10.2021 | Сиш | 03:50 | 04:24 | 05:54 | 11:31 | 12:00 | 15:09 | 17:08 | 18:49 |
| 06.10.2021 | Чәрш | 03:52 | 04:26 | 05:56 | 11:31 | 12:00 | 15:07 | 17:06 | 18:47 |
| 07.10.2021 | Пәнҗ | 03:54 | 04:28 | 05:58 | 11:31 | 12:00 | 15:04 | 17:03 | 18:44 |
| 08.10.2021 | Җом | 03:56 | 04:30 | 06:00 | 11:31 | 12:00 | 15:02 | 17:00 | 18:41 |
| 09.10.2021 | Шим | 03:58 | 04:32 | 06:02 | 11:30 | 12:00 | 15:00 | 16:58 | 18:39 |
| 10.10.2021 | Якш | 04:00 | 04:34 | 06:04 | 11:30 | 12:00 | 14:58 | 16:55 | 18:36 |
| 11.10.2021 | Дүш | 04:02 | 04:36 | 06:06 | 11:30 | 12:00 | 14:55 | 16:53 | 18:34 |
| 12.10.2021 | Сиш | 04:04 | 04:38 | 06:08 | 11:29 | 12:00 | 14:53 | 16:50 | 18:31 |
| 13.10.2021 | Чәрш | 04:07 | 04:40 | 06:10 | 11:29 | 12:00 | 14:51 | 16:48 | 18:29 |
| 14.10.2021 | Пәнҗ | 04:09 | 04:42 | 06:12 | 11:29 | 12:00 | 14:49 | 16:45 | 18:26 |
| 15.10.2021 | Җом | 04:11 | 04:44 | 06:14 | 11:29 | 12:00 | 14:46 | 16:43 | 18:24 |
| 16.10.2021 | Шим | 04:13 | 04:46 | 06:16 | 11:29 | 12:00 | 14:44 | 16:40 | 18:22 |
| 17.10.2021 | Якш | 04:15 | 04:48 | 06:18 | 11:28 | 12:00 | 14:42 | 16:38 | 18:19 |
| 18.10.2021 | Дүш | 04:17 | 04:50 | 06:20 | 11:28 | 12:00 | 14:40 | 16:35 | 18:17 |
| 19.10.2021 | Сиш | 04:18 | 04:52 | 06:22 | 11:28 | 12:00 | 14:38 | 16:33 | 18:15 |
| 20.10.2021 | Чәрш | 04:20 | 04:54 | 06:24 | 11:28 | 12:00 | 14:35 | 16:31 | 18:12 |
| 21.10.2021 | Пәнҗ | 04:22 | 04:56 | 06:26 | 11:28 | 12:00 | 14:33 | 16:28 | 18:10 |
| 22.10.2021 | Җом | 04:24 | 04:58 | 06:28 | 11:27 | 12:00 | 14:31 | 16:26 | 18:08 |
| 23.10.2021 | Шим | 04:26 | 05:00 | 06:30 | 11:27 | 12:00 | 14:29 | 16:24 | 18:06 |
| 24.10.2021 | Якш | 04:28 | 05:02 | 06:32 | 11:27 | 12:00 | 14:27 | 16:21 | 18:04 |
| 25.10.2021 | Дүш | 04:30 | 05:04 | 06:34 | 11:27 | 12:00 | 14:25 | 16:19 | 18:02 |
| 26.10.2021 | Сиш | 04:32 | 05:06 | 06:36 | 11:27 | 12:00 | 14:22 | 16:17 | 17:59 |
| 27.10.2021 | Чәрш | 04:34 | 05:09 | 06:39 | 11:27 | 12:00 | 14:20 | 16:14 | 17:57 |
| 28.10.2021 | Пәнҗ | 04:36 | 05:11 | 06:41 | 11:27 | 12:00 | 14:18 | 16:12 | 17:55 |
| 29.10.2021 | Җом | 04:38 | 05:13 | 06:43 | 11:27 | 12:00 | 14:16 | 16:10 | 17:53 |
| 30.10.2021 | Шим | 04:39 | 05:15 | 06:45 | 11:27 | 12:00 | 14:14 | 16:08 | 17:51 |
| 31.10.2021 | Якш | 04:41 | 05:17 | 06:47 | 11:27 | 12:00 | 14:12 | 16:05 | 17:50 |

**17 октябрь / 11-12 рабигыль-әүвәл – Мәүлид кичәсе (пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган кичәсе)**

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Сентябрь саны, №9 (314)*

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л. Г.**, **Юлдашева А. И.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2539
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче сентябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 27 нче сентябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.

12+